СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.03.2018 с. Куралово 34-151

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 27-117 номерлы Куралово авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып, Югары Ослан районының прокурорының 09.01.2018 № 02-07-02 протестын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
карар итте:

1.«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017 елның 27 сентябрендәге 27-117 номерлы Куралово авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Әлеге карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләре (өлешләре) өчен бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә»;

1.1. Әлеге карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлау буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы»;

2.Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Л.И.Коткова